**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 02.02.2023** **№ 204**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2022 елның 30 гыйнварындагы номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елның 1 февраленнән Биектау муниципаль районында җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 7793,48 сум күләмендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 01 февралендәге 188 номерлы «Җирләү буенча гарантияләнгән исемлек хезмәтләрнең күрсәтүнең тарифларын раслау турында» карарын 2023 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта

Биектау муниципаль
районы башкарма
комитетының 2023 елның 2
феврале номерлы карары
белән расланды

ТР Биектау муниципаль районында 2023 елның 1 нче февраленнән җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлегенең
бәясе

| **Хезмәтләр исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | түләүсез |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4544,52 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 1033,77 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2215,15 |
| **Барлыгы** | **7793,48** |

2 нче кушымта

Биектау муниципаль
районы башкарма
комитетының 2023 елның 2
февраленомерлы карары
белән расланды

ТР Биектау муниципаль районында 2023 елның 1 нче февраленнән җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлегенең
бәясе

| **Хезмәтләр исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | түләүсез |
| 2. Кәфенләү | 590,73 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3953,80 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 1033,18 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2215,18 |
| **Барлыгы** | **7793,48** |